Батырлык дәресе **: “Әфганстан –йөрәк ярасы”**

**9нчы сыйныфның класс җитәкчесе Галиәхмәтова Чулпан Илсур кызы.**

**Максат:** Укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирү, Ватанның белән горурлану, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Бурычлар:** 1.Укучыларга Әфганстан сугышы һәм аның илебез халкына алып килгән югалтулары турында төшендерү;
2. Әфганстанда хәрби хезмәттә булган егетләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү иҗади активлык, бердәмлек тәрбияләү;
3.укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү һәм сәхнә оталыгына өйрәтү.

**Җиһазлау:** музыка,презентация
Класс сәгатенең барышы:
**1нче укучы**: Әфганстан, исемең шигъри синең,
Җирең сихри, кыя, ташларың!
Изге дуслык бурычын үтәр өчен
Сиңа китте бик күп якташларым...
Кыяларның булмый ак таплары,
Аларның була тик ак ташлары.
Шул ташларны каннарына манып,
Табутларда кайтты якташларым.

**Алып баручы:** “Әфган сугышы” “Әфганда хезмәт иткән. Сугышчы-интернационалист”дигән төшенчәләрне ишетергә туры килә.Кайчан булган соң ул Әфган сугышы? Кемнәр ул сугышчы- интернационалистлар? Бүген без шул сорауларга җавап эзләрбез.

Әфганстан СССРның күршесе була, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң ул нейтраль дәүләт булып санала. Башкаласы- Кабул шәһәре.Менә шушы илдә 1978 елның 27 апрелендә милли-демократик революция, ә чынында исә законлы властьне хәрби көчләр ярдәмендә бәреп төшерү була. Хакимияткә Әмин килә. Ул АКШ мәнфәгатьләрен яклый. Әфганстанны СССРга каршы плацдарм итеп файдаланырга телиләр.1979нчы елның декабрендә Брежнев, Суслов, Андропов, Громыко белән киңәшләшкәч, Әфганстанга совет гаскәрләрен кертергә була.

"Бөтен дөньяда тынычлык һәм демократия өчен ару-талу белмәс көрәшүче Л.И.Брежнев Әфганстанга совет гаскәрләре кертелү турындагы хәбәрне үзәк телевидение буенча шәхсән үзе 1979 елның 27 декабрендә игълан итә. Әфганстанга совет гаскәрләре кергәннең икенче көнендә үк аларның сугышчан хәрәкәтенә җитәкчелек итү өчен Мәскәү тарафыннан маршал Соколов белән генерал-полковник Могометов озатыла.

**Галяутдинов Нияз башкаруында җыр.**

1980 елда Әфганстан җирендә-1500, 1981-1300, 1982 - 2000гә якын совет сугышчысы һәлак була. Яралыларның саны уннарча меңнәргә җитә. Күпме егет туган туфракларына кургаш кәфенлеккә төренеп кайта. Ә бит алар мәктәп партасыннан әле генә аерылган 17-18 яшьлек егетләр. Әфганлылар җәмгыяте икегә аерыла: беренчеләре- совет гаскәрләрен азат итүчеләр итеп күрсә, икенчеләре өчен безнең солдатлар-басып алучылар. Кабул хөкүмәтенә каршы төркемне маджахитлар дип йөртәләр.Рус солдатларын алар “шурави” дип йөртә. Аларга Пакистан, Сәгүд Гарәпстаны, АКШ булыша. 1988 елның 15 маенда

гына чит илдәге гражданнар сугышыннан совет гаскәрләре чыгарыла башлады һәм ниһаять 1989 елның 15 февралендә соңгы совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыкты. Бүген 15нче февраль- сугышчы- интернационалистлар көне. Әфган сугышы тәмамлануның 24 еллыгы.

Брежнев хөкүмәте башлаган "тантаналы марш" безнең халык өчен 15 меңгә якын кургаш табут, 36 мең яралы, 312 хәбәрсез югалган солдат рәвешендә әйләнеп кайтты. Әфган мәхшәрен безнең илнең 520 меңгә якын сугышчысы кичеп чыкты.
Татарстан республикасы Әфган сугышында менә дигән 260 егетен югалтты.

Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Әмма без тарихтагы бу кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгелбез. Гомерләренең иң матур вакытында һәлак булган егетләребезнең намус һәм хәрби бурыч төшенчәләрен үзләренең тормышыннан да өстенрәк куйганнары өчен горурлану тойгысы кичерәбез. Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши.

Тын калыйк бер минут, бары тик бер минут,
Бар дөнья бер минут тын калсын.
Ах, Әфган җилләре һәм дала гөлләре...
Чык түгел, гөлләрдән яшь тамсын!(бер минут тынлык)

**2нче укучы:**

“Кайсы тауның ташларыннан икән

Батырлыкка һәйкәл куясы!”

“Ил өстендә бөтерелеп

Йөрсә хәвеф-хәтәр,

Бу инде “батырларча...” дип

Килгән соңгы хәбәр”.

“Батырлык, дип күпме сөйләп йөрмик,

Күпме аны күккә күтәрмик,

Ише бармы бөеклекнең солдат

Кылган батырлыкка тиңләрлек?”

**Бию “Кызыл чәчәкләр”**

**3нче укучы**: Ярдәм сорап күп килделәр безгә

Барысына да бу ил булышты.

Тик беләсе иде –

Без соң тагын кайсы илгә күпме бурычлы?

Интернациоаналь бурыч дидек

Әллә нәрсә итеп сөйләдек

Бурычтырмы...

Нигә меңәрләгән

Кеше җаны белән түләдек?!

 Япь-яшь кенә килеш күпме гарип

Аналарның йөрәк түземме?

Бурыч түләр өчен егетләрнең

Аяк-кулы кирәк идеме?

Илдә нигә кадерсезләнделәр

Бурыч түләде бит алар да.

Ахыр чиктә йөрәкләргә нигә

Граната булып ярыла?!

Интернациональ бурыч имеш

Табалмадык шуннан башканы

Ил бурычы булып, әсирлектә

Газап чигә кемнең башлары.

Тагын кемгә, күпме бурычлы без

Нигә белми халык?

Бүгенге яңа буын егетләре үсә

Бурыч түләр өчен түгелме?

(Х.Әюп. Интернациональ бурыч)

**Алып баручы:** Шуңа сөеник, исән кайткан солдатлар арабызда яши. Әфган егетләре... Аларны тикмәгә генә шулай атамыйлар. Чөнки алар туган илгә кайткач та әфган егетләре булып калдылар. Алар ут-суны кичеп, язмышларына төшкән авырлыкларны, сынауларны бергә җиңеп чыгып, бирелә дә бер-берсе белән элемтәне өзмәделәр. Алар бүген гаиләле, тырыш ирләр.

Алар авылдашларыбыз Исмәгыйлев Нурхәт Мөхәммәт улы, Сәмигуллин Рамил Котдүс улы,Сираев Рәфик Якуб улы,Шәмсиев Фәрит Фәрух улы, Коркачык авылы егетләре

Гыйльфанов Камил Шамил улы, Сәмигуллин Зөфәр Юныс улы, Ибраһимов Айрат Муса улы.

Алар белән якыннан танышып үтик. Презентация.

**Исмәгыйлев Нурхәт Мөхәммәт улы** 1984нче елның апрелендә армиягә алына, Әфганга эләгә. Тау арасында дошманнар белән сугыша. Ком өстендә йоклыйлар. Көндез эссе, төнлә салкын.

**Сәмигуллин Рамил Котдүс улы** 1984-1986нчы елларда Әфганстанда Кандагар шәһәрендә хезмәт итә. Ашау начар, су юк, эссе. Кичен засадада, ә көндез кишлаклардан дошманны эзләү. Рамил гранатаметчы, өлкән стрелок, старший водитель була.

**Сираев Рәфик Якуб улы** 1987нче елда армиягә алына. Присяга кабул иткәч, Әфганстанның Мазари-Шәриф шәһәрендә минометчик булып хезмәт итә. Ачык һавада палаткаларда куналар, шәһәрне дошманнан саклыйлар. 1989нчы елның 16нчы маенда туган авылына кайта. Хатыны Әлфия белән ике кыз үстерәләр.

**Шәмсиев Фәрит Фәрух улы** 1978нче елның 30нчы мартында хәрби хезмәткә алына. Курган-Түбә шәһәрендә 3ай учение үтә. Вертолетларга төяп, Поле-Хмури шәһәренә алып киләләр.Су эчәргә, юыныргга тилмерәләр. 1айга бер тапкыр мунча эләгә. Зенитный ротада хезмәт итә. Температура 50 градустан югары. БТР танкларыны утырып, сугышка керәләр. Кайтырга 6 ай кала, ягына пуля эләгә.Госпитальдә ята. 1984нче елның июлендә туган авылга әйләнеп кайта. Тормыш иптәше Венера белән бер кыз, бер ул үстерәләр. Бүгенге көндә оныгы Рания үсеп килә.

**Гыйльфанов Камил Шамил улы** 1982нче елда армиягә алына. Бишкек шәһәрендә 3ай хәрби өйрәнүләрдә була. Аннары Кабул шәһәрендә 1984нче елның августына кадәр хезмәт итә. 30 августта коркачыкка кайта. 1996нчы елдан Чыпчык мәктәбендә директор булып эшли.Өйләнгән, ике баласы бар.

**Сәмигуллин Зөфәр Юныс улы** Ямаширмә мәктәбен тәмамлагач, 1983нче елда Әфганстанга эләгә. Шофер булып хезмәт итә."Воину-интернационалисту от благодарного Афганского народа" медалебелән бүләкләнә. Исән-сау әйләнеп кайта.

**Ибраһимов Айрат Муса улы** 1983нче елның 29нчы сентябрендә армиягә алына.1983нче елның декабрендә Кабулга эләгә. Анда 2ел сержант булып хезмәт итә.Сугышта якын дусларын югалта.1985нче елның 5нче ноябрендә хезмәтен тәмамлап кайта. Өйләнгән, хатыны Раушания белән бер ул, бер кыз үстерәләр.

**Алып баручы**: Зур сугышлар бетә, ә тарих мәңгелек. Әфган сугышы да тарихыбызга кереп калды.

Кешенең матурлыгы үз Ватанын яратуда, аны һәр минутта сакларга әзер булуда чагыла. Ватанны ярату – аның уңышлары белән горурлану, үз халкыңа файдалы булу, аңа яхшы яшәргә комачаулаучы барлык нәрсә белән көрәшү дигән сүз. Тормышта һәрчак батырлыкка урын бар, тик аңа юл үзеңдә бурычлылык хисе, сәяси өлгергәнлек, җаваплылык, әхлакый тотрыклылык тәрбияләү аша үтә. Кешенең героик характеры үзендәге начар сыйфатларны җиңүдән башлана.

Хөрмәтле кунаклар, укучылар!

Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын. Яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен, ата-аналар кайгы яше түкмәсен иде. Кеше бу дөньяга иҗат итү, җирне матурайту өчен яратылган. Без – тынычлык яклы!

*Җыр."Тынычлык"*